

Илебездә 2013 елдан алып жирле vзидарә коне билгеләп vтелә. Бу vз язмышларын муниципаль хезмәттә эшләv белән бәйләгән кешеләр бәйрәме. Беренче чиратта - авыл жирлекләре администрацияләре хезмәткәрләре һәм аларнын башлыклары коне. Шундый хезмәткәрләрнен берсе кvп еллар буе Ромодан районы Алтар авыл жирлеген житәкләгән кеше, Менир Хафиз улы Кузяев турында сойләргә телибез.

Авылда хезмәт эшчәнлеген Менир Хафиз улы 1991 елда «Шефная звезда» колхозы рәисе урынбасары итеп башлый, шул вакыт анын рәисе Гафият Рафат улы Аширов була. 1996-98 елларда, Г.Р.Ашировтан сон, Бясыр Исхак улы Нугаев эшли. Аннары 1998-2000 елга кадәр Яфуняев Менир Равильевич житәкләп ала.
Гафият Рафатович Аширов инициативасы белән, авыл хужалыгы предприятиесендә инкубатор, кош-корт фермасы тозелә; анда иткә кош-корт һәм йомырка житештерәләр. Менир Хафизович, кошчылык очен махсус жиһазлар сатып алу очен, Украинадагы Нежин шәһәренә барып, жиһазлар - оборудование китерә. Хужалык шулай ук ит, сот, бортекле һәм техник культуралар житештерә. Моннан тыш, ит эшләнмәләре, казылык һәм куертылган сот житештерv жайга салына. 2002 елдан башлап хужалык «АПО Элеком» жәмгыятьчелек бvлекчәсе була.
2000 елда Менир Хафиз улын жирле vзидарә башлыгы, ә 2006 елда Алтар авыл жирлеге администрациясе башлыгы итеп билгелиләр. Ул эш елларын жылы искә ала, гәрчә мәшәкатьләр дә кvп булса да.
- Мин vз вазыйфамны 20 ел элек алдым, һәм газлаштыру авыл халкынын тормыш сыйфатын яхшырту очен беренче чираттагы бурыч булды. Газ челтәренә шәхси йортлар, мәктәп, медпункт, аннары авыл жирлеге администрациясе һәм мәдәният йорты тоташтырылды, - дип анлатты Менир Хафизович. - Бvгенге кондә ботен авыл буенча газ vтә, торак фонднын 98% газ белән тәэмин ителгән. Безнен жирлектә ике процент яшь гаиләләр йортлар този. Сvз унаенда, агымдагы елнын беренче айларында авылда дvрт бала туды.
Хәзер жирлек территориясендә 980 кеше яши - бу 365 хужалык, шуна кvрә эш һәрвакыт житәрлек. Авылдашларынын тормышын унайлы итv очен бередә тозекләндерv эшләре белән ныклап шогыльләнәләр. Берничә ел элек «Авыл территорияләрен комплексы

vcтерv» программасы буенча 7,5 км суvткәргеч челтәр тозелгән, яна су башнясы урнаштырылган. Первомайский урамын, зәрәтләргә кадәр һәм Советская урамын, республикабызда бердән-бер Советлар вакытында да эшләп килгән мәчеткә кадәр тозелде. Салкыннарга кадәр, район житәкчесе һәм авыл халкы хатлары нәтижә бирсә, Октябрьская урамындагы юлны, перекресткага кадәр, барлыгы 500 метрны ремонтларга кирәк булачак.
Менир Хафизовичнын даими кон- тролендә авылнын социаль объектлары: медицина пункты, ул эшләгән елларда тозелгән, мәктәп, авыл мәдәният йорты тора. Аларда да янарыш бара. Шулай итеп, Алтар мәдәният йортында жылылык системасын тулысынча алыштырганнар, коллектив откан грантка заманча жиһазлар сатып алганнар. Ә бер ай элек кенә, мәктәпнен «Туган якны ойрәнv» музеенын капиталь ремонт vткәрелгән яна экспозициясе ачылды.
- Менир Хафизович, кон кадагында торган пандемия турында да әйтеп китәр идегез?
- Пандемия вакытында без башка тобәкләрдән килгән авыл халкы белән дә элемтәгә кердек. Барлык саклык чараларын vтәргә һәм ике атналык карантин вакытында ойдә калырга кирәклеген анлаттылар. Азык - толек белән кибеткә мохтаж олкән яшьтәге кешеләргә волонтерлар йорде, - дип уртаклашты Менир Хафизович. - Якташлар мәжбvри чараларга бик теләп карадылар. Бу олкәдә проблемалар тумады.
Жирлектә мәшәкатьләр кvп. Язгы жылы коннәр башлану белән дә проб- лемалар артты. Авыл халкы йорт яны территорияләрен жыештыруга кереште һәм коры vлән яну куркынычы туды. Рес- публикабыз буенча да шунын аркасында янгыннар чыгуны ишетеп тордык. Ә Алтарда хәлләр башкача тора, Менир Хафиз улы Кузяев монын турында:
- Бәхеткә, жирлектә янгын сvндерv машинасы һәм ирекле янгын дружинасы бар; алар янгын учагын сvндерv очен санаулы минутларда, килеп житәләр, шалтырату алгач ук, - дип билгеләп vтте Менир Хафизович.
Сонгы ике ел эчендә авылда 15 урам яктырту ноктасы урнаштырылган, хәзер урамнарда тәvлекнен карангы вакытында якты була. «Без тормышны унайлырак итv очен авыл халкы очен эшлибез», - дип остәде башлык.
Узган ел Мордовия Республикасы житәкчелеге һәм Дәvләт Советы депутаты А.И.Атласов ярдәме белән «Ро- моданово-Алтар-Белозерье» юлына капиталь ремонт ясалган, шулай ук анын спонсорлык ярдәме белән авыл юлларында чокырлар да ремонтланган.
Алтар авыл жирлеге бюджетына 340 жир пай жирләреннән салым керә, алар бу жирләрне арендалаучы «Элеком» жәмгыятьчелеге тvли. Жир салымы шулай ук Р.А.Ишкининнан да керә; ул берничә ел элек гранд отты һәм дәvләттән vсеш очен субсидия алды. Шул акчага техника һәм эре могезле терлек сатып алган. Фермер 9 га мәйданда азык культуралары vстерә. Моннан тыш, жир һәм милек очен халыктан да салымнар керә.
Быел кыш юл читендә авыл халкы чvп белән тутырылган пакетлар калдыру турында Менир Хафизович белән сойләгән идек, ә мин «Юлдаш»та язган идем. Бу ситуацияне авыл житәкчесе тозәтергә ышандырды. Әйткән сvз - каккан казык, дигәндәй, шулай булды да.
«Агымдагы елнын беренче апрелен- нән авыл жирлегендә «Ремондис» компаниясе тарафыннан каты конкvреш калдыкларын чыгару оештырылды, чvп тартмалары куелды. Хәзер ин кимендә 400 мен сум акча шул тартмалар мәй- данчыгын тозекләндерv очен кирәк», - дип уртаклашты Менир Хафизович.

2023 елда авыл жирлеге, Алтар авылынын ижтимагый территорияләрен тозекләндерv очен, «Заманча шәһәр тирәлеген формалаштыру» муниципаль программасында катнашырга планлаштыра. Моннан тыш, Октябрь урамы буенча автомобиль юлын ремонтлау да каралган. Планнары бар, авыл жирлеге хезмәткәрләре тырышлыгы белән алар тормышка ашырылыр дип ометләнәбез.
Барысын да Алтар авылы халкы очен эшлиләр.

**Наилә НАСЫРОВА**